# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге составына керүче Иске Мочалкино торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдаланумәсьәләсе буенча гражданнар жыены нәтиҗәләре турында

№ 2 «04» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчестатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино торак пунктында 2020 елның «04» ноябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар жыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Иске Мочалкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021елда биш йөз сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Иске Мочалкино торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Иске Мочалкино торак пунктына урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар жыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыендакатнашучыла рисемлегенә 30 кеше кертелгән;
гражданнарҗыенында тавыш бирүдәкатнашучылар саны: 20 кеше, 66,7 % тәшкил итә:
Гражданнарҗыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 20 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Иске Мочалкино торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга:«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Иске Мочалкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда биш йөз сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Иске Мочалкино торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Иске Мочалкино торак пунктына урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү)

3. Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков